күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

5нче чыгарылыш
31 нче гыйнвар

БУ САНДА:


Мәктәп яңалыклары 1
Эшлекле әңгәмә 2
«Халыклар дуслыгы” көне 3
Котлыйбыз! 4

## Мәктәп яңалыклары...

**25 нче гыйнвар көнне, чемпионатка әзерлек кысаларында, мәктәбебез Канада вәкилләрен каршы алды. Кунакларны ипи-тоз, чәк-чәк белән каршы алдылар. Алар мәктәбебез буйлап сәяхәт кылдылар:ашханә, бассейн, хезмәт кабинетында, актлар залында булдылар. WorldSkills Kazan 2019 дәресен карадылар.**
**Канада вәкилләре концерт,бадминтончылар, футболчылар,синхрончыларның чыгышларын карап хозурландылар.**
**Очрашу түгәрәк өстәл артында, август аена планнар кору белән тәгәлләнде.**
**Канада вәкилләре бу очрашудан бик канәгать калдылар.**







# Эшлекле иртәнге аш



17 нче гыйнвар көнне Татарстан Республикасының Югары судьясы  Шемуранов Александр Николаевич белән эшлекле очрашу узды.

Александр Николаевич укучыларны үзенең тормыш юлы белән  таныштырды.

«...Мин авылда тудым, сыйныф җитәкчесе ярдәмендә юрист булдым, дисәм дә ялган булмас. Кызганыч, ул арадан китте инде. Ул миңа: «тырышма, синнән юрист булмаячак», -диде. Бу сүзләр миңа этәргеч булды.Шуннан соң бик тырышып укыдым, бер генә «4»ле чыкты. Ул мина әлеге сүзләрен әйтмәсә, мин максатыма ирешмәс идем.Укырга кердем, институт тәмамлагач, прокуратората эшкә урнаштым. Прокурор ярдәмчесе булып эшләдем.

2009 нче елдан хәзерге вазыйфамны башкарам…».

Александр Николаевич укучыларны үзенең эш режимы, шөгыле белән таныштырды. Аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

Укучылар очрашудан бик канәгать калдылар.

Газета хәбәрчесе  Вәлиева Диләрә





24 нче гыйнварда мәктәбебездә чираттагы “Эшлекле очрашу”

( “Деловой завтрак”) узды. Бездә кунакта- Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты, Татарстанның халык артисты Илдар Зиннурович Хайруллин булды. Балалар күренекле артистыбызны зур кызыксыну белән тыңладылар, сораулар бирделәр.

Илдар Зиннурович укучыларга, тормышта уңышка ирешү өчен, тырышып укырга, ялкауланмаска, тәртипле булырга кирәклеге турында сөйләде. Туган телдә сөйләшергә, китаплар күп укырга, тарих, әдәбият белән кызыксынырга кирәклеге турында ассызыклап әйтте. Мөхтәрәм артистыбыз укучыларның театр турында, “ничек артист булырга”, “ничек зур уңышка ирешергә” кебек сорауларына җавап бирде.





Газета хәбәрчесе  Мәхмүтова Мәдинә

# «Халыклар дуслыгы» көне

Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә. Шулай ук чуашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ.б. халык вәкилләре дә бар.
Татарстан халыклары үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә, тел, мәдәният һәм башка өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, күркәм тормыш итәләр. Аларның киләчәккә омтылышлары, уй-хыяллары бер-берсенә охшаган кебек…




29 нчы гыйнвар көнне мәктәбебездә, 5-8 нче сыйныфлар арасында, «Халыклар дуслыгы» көне узды.
Максаты: укучыларны төрле милләт вәкилләренең тарихы, халык авыз иҗаты, яшәү үзенчәлекләре белән таныштыру; аларга карата толерантлылык тәрбияләү.
Бу көн бик күңелле, мәгънәле узды.
Һәр сыйныф бер милләт вәкилен тәкъдим итте. Киемнәрен киеп, җыр-биюләрен һәм уеннарын күрсәтеп чыгыш ясадылар.
Милли ризыклары белән түгәрәк өстәлләрен бизәделәр.

Газета хәбәрчесе
Мельникова Аделина









## Истәлекле даталар

*Рәссам Валентин Михайлович Быковскийның тууына 60 ел (1959–2015) -1.02
*Күренекле тарихчы, профессор Степан Васильевич Ешевскийның тууына 190 ел (1829–1865) -2.02
*Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең (Муса Мостафа улы Җәлилов )тууына 113 ел (1906-1944)-15.02
*Тәрҗемәче, педагог Фәридә Бижан кызы Ситдыйковага 60 яшь (1959) -18.02
*Язучы, Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе лауреаты Владимир Николаевич Лавришкога 75 яшь (1944) -29.02
*Журналист, язучы Фәнзаман Баттал (Фәнзаман Сәетбаттал улы Сәетбатталов)ның тууына 80 ел (1939–2015) -16.02

## Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Абдуллина Динә Альберт кызы (09.02)

Батыршина Миләүшә Рубис кызы (09.02)

Гордеева Дарья Вячеславовна (15.02)

Воронина Юлия Алексадровна (21.02)

Нәҗмиева Диләрә Илдар кызы (23.02)




## Хөрмәтле газета сөюче укучыларыбыз!

Сезнең игътибарыгызга “ Кем тизрәк табар?” уенын тәкъдим итәбез.

1. Үзбәкстанда яши торган халык теле.
2. Азиядәге утрауларда яши торган халыклар теле.
3. Элекке СССРның көнбатышындагы республикада яшәүче халык теле.
4. Рус теленә бик охшаш телләрнең берсе.
5. Урта Азиядә татар теленә кардәш тел.
6. Урта Азиядәге милләт теле.
7. Татарстанда һәм чиктәш республикада яши торган халык теле.
8. Илебездә халыкларның күпчелеге сөйләшә торган тел.

Җавапларыгызны көтеп калабыз!

Газета хәбәрчеләре

Баш мөхәррир: Абрамова Д.
Дизайнер: Хәйриев С.
Техник редактор: Мәхмүтова М.
Мөхәррир: Валиева Д.
Корректор:Мельникова А.
Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru
Компьютерда җыючылар:Хөснетдинова К.
Гамәлгә куючылар:укучылар иҗат үзәге
Адрес:Тулпар урамы, 2нче йорт